ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**05.06.2017**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 1650**

Зеленодольск муниципаль районының 2013-2016 еллардагы авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү программасы буенча торак йортларны коммуникацияләрдән өзү турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 31 июлендәге «Зеленодольск муниципаль районының авария хәлендәге күпфатирлы йортлар исемлеген раслау турында» 1553 номерлы карары нигезендә, шулай ук бинаны торак урын, торак урынны даими яшәү өчен яраксыз дип тану буенча ведомствоара комиссиясенең Клуб тыкрыгы урамы, 12 нче йорт буенча 2009 елның 9 октябрендәге 298 номерлы , Волгоград урамы, 1 нче йорт буенча 2009 елның 7 октябрендәге 236 номерлы, Подгорная урамы, 3 нче йорт буенча 2009 елның 5 октябрендәге 182 номерлы бәяләмәләре буенча, Россия Федерациясе Гражданлык кодексы, Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы «Бинаны торак урыны, торак урыны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы нигезләмәне раслау хакында» 47 номерлы карарына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Зеленодольскгаз» ЭПУ , «Водоканал» ААҖ, Зеленодольск ОКО Идел буе бүлекчәсе - «Татэнергосбыт» ААҖ түбәндәге адреслар буенча тиешле төр йортларны коммуникацияләреннән өзәргә:
Зеленодольск шәһәре, Клуб тыкрыгы урамы, 12 нче йорт;
- Зеленодольск шәһәре, Волгоград урамы, 1 нче йорт;
Зеленодольск шәһәре, Подгорная урамы, 3 нче йорт.
2. «Зеленодольск муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалык департаменты» МБУ түбәндәге адреслар буенча торак урыннарның социаль найм килешүләрен өзәргә:
Зеленодольск шәһәре, Клуб тыкрыгы урамы, 12 нче йорт;
- Зеленодольск шәһәре, Волгоград урамы, 1 нче йорт;
Зеленодольск шәһәре, Подгорная урамы, 3 нче йорт.

3. «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ билгеләнгән тәртиптә Зеленодольск шәһәренең муниципаль милек реестрыннан югарыда күрсәтелгән йортларны төшереп калдыруны тәэмин итәргә, «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасына күчерелгән йортларга җир кишәрлекләрен тапшырырга.

4. ЗМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгы Д.С. Анисимовка әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы сайтында яисә «Зеленодольская правда» газетасында бастырып чыгаруны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин